ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 июля 2017 г. № 4092

Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы под-1389/15 номерлы боерыгы белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 9 июнендәге под-1049/17 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3251 номерлы, 2017 елның 3 маендагы 2748 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, 3.6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3.6.6. Бер Оешмага йөри торган баланы башка Оешмага исәпкә кую өчен гаризадагы мәгълүматларны Системага керткәндә, ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан тиешле гаризаны бирү датасы куела.

Оешмаларны комплектлаштырганда гаризалар чират тәртибендә карап тикшерелә.

Ташламалы категория гражданнарның бер Оешмага йөрүче балалары башка Оешмага исәпкә куелганда, федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка закон актларында билгеләнгән ташламалардан файдалана.».

2. Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы В.Х. Харисовка әлеге карарны «Интернет» челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Р.Ә. Абдуллин